МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.07.2020 г. Казань № 444 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Тантана» («Триумф») Еллык театр конкурсы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы премиясе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 16 февралендәге 89 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

**БОЕРАМ:**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Тантана» («Триумф») Еллык театр конкурсы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының премиясе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 16 февралендәге 89 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 24 гыйнварындагы 59 од номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Тантана» («Триумф») Еллык премиясен оештырырга һәм түбәндәге номинацияләрнең һәркайсы буенча 100000 сум күләмендә билгеләргә: «Дебют», «Иң яхшы эпизодик роль», «Курчак театрының иң яхшы актеры», «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле», «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле», «Намус һәм дәрәҗә (Һөнәргә тугрылык өчен)», «Музыкаль спектакльдә иң яхшы роль», «Актерлар ансамбле өчен», «Иң яхшы хатын-кыз роле», «Иң яхшы ир-ат роле», «Балалар өчен иң яхшы спектакль», «Иң яхшы театр тәнкыйтьчесе»;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының еллык театр конкурсы һәм «Тантана» («Триумф») премиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 16 февралендәге 89 номерлы боерыгы белән расланган «Тантана» («Триумф»)

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының еллык театр конкурсы һәм «Тантана» («Триумф») премиясе турындагы Нигезләмәдә:

3.1 пунктындагы унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иң яхшы театр тәнкыйтьчесе»;

4.1 пунктында «Ел вакыйгасы» сүзләрен «Иң яхшы театр тәнкыйтьчесе» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктында «Ел вакыйгасы» һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.5 пунктын өстәргә:

«4.5. «Иң яхшы театр тәнкыйтьчесе» номинациясендә Татарстан Республикасында эшләүче тәнкыйтьчеләр катнаша, алар түбәндәге критерийларга туры килә:

театр югары уку йортының һөнәри белеме булу (белгечлеге - «Театр сәнгате», «Театраль тәнкыйть», «Театр сәнгате һәм драматургия», «Театраль сәнгать»);

театр рецензияләре булу, махсус (һөнәри) массакүләм мәгълүмат чараларында язмалар булу;

театр сәнгате мәсьәләләренә багышланган театраль конференцияләрдә һәм форумнарда лектор/спикер сыйфатында катнашу;

Премиянең дәгъвачысы профильле фәнни берләшмәләрдә тора.»;

5.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тәнкыйтьчеләргә шулай ук «Иң яхшы театр тәнкыйтьчесе» номинациясе буенча үз кандидатурасын тәкъдим итү хокукы әлеге Нигезләмәнең 4.5 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килә торган очракта бирелә. »;

5.3 пунктында «1 февральдән дә соңга калмыйча» сүзләрен «1 марттан да соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Спектакльне тәкъдим итү өчен Союз һәм театрлар һәр календарь елның 2 мартыннан да соңга калмыйча Министрлык адресына: 420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 йорт (белешмә өчен телефон: 8 (843) 264 74 73) түбәндәге документларны тапшыралар:

театр исемен, спектакль/спектакльләрнең исемнәрен һәм премьераның төгәл датасын, «Намус һәм дәрәҗә (Һөнәргә тугрылык өчен)» номинациясендә Премиянең дәгъвачысын күрсәтеп, җитәкче тарафыннан имзаланган һәм билгеләнгән тәртиптә мөһер белән таныкланган гариза;

спектакльнең теләсә кайсы электрон чыганакта тулы язмасы;

спектакльнең буклеты;

спектакль турында белешмә;

массакүләм мәгълүмат чараларында басмалар.

«Иң яхшы театр тәнкыйтьчесе» номинациясе буенча үз кандидатурасын тәкъдим итү өчен әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срокларда тәнкыйтьчеләр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

үз куллары беләν имзаланган һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган гариза: анкета мәгълүматлары (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы, туган урыны, теркәлү адресы, белеме, эш урыны, вазыйфасы), булган бүләкләре һәм мактаулы исемнәре, массакүләм мәгълүмат чараларында рецензияләрнең басмалары, лектор/спикер сыйфатында театр конференцияләрендә һәм форумнарда катнашу турында мәгълүмат;

театр югары уку йортын һөнәри белем бирү турындагы диплом күчермәсен;

паспорт яисә шәхесне таныклый торган башка документ күчермәсен;

Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча физик затның салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсен, яисә индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт китабы күчермәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

Премиягә дәгъва кылучының спектакль/спектакльләргә рецензиясе.

Икенче этап.»;

5.5 пунктына «, гаризалар һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар» сүзләрен өстәргә;

5.6 пунктының беренче абзацында «Спектакльләрне карау нәтиҗәләре буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Икене этап нәтиҗәләре буенча Премиягә дәгъва кылучыларны билгеләү өчен «Дебют», «Иң яхшы эпизодик роль», «Курчак театрының иң яхшы актеры», «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле», «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле», «Намус һәм дәрәҗә» (Һөнәргә тугрылык өчен), «Музыкаль спектакльдә иң яхшы роль», «Актерлар ансамбле өчен», «Иң яхшы хатын-кыз роле», «Иң яхшы ир-ат роле», «Балалар өчен иң яхшы спектакль» номинацияләре буенча катнашучы спектакльләр Министрлыкка 15 марттан башлап 20 марттан да соңга калмыйча түбәндәге документларны кертә:

Премиягә дәгъва кылучы турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган театр җитәкче исеменнән гариза: анкета мәгълүматлары (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы, туган урыны, теркәлү адресы, белеме, эш урыны, вазыйфасы), тулы иҗади характеристика, тәкъдим ителә торган

роль/спектакль буенча белешмә, спектакльдән фото (5 данә), Премиягә дәгва кылучының фотосы, мәкаләләр һәм массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту, театр җитәкчелегенең хезмәткәрне Премиягә тәкъдим итү турындагы хаты;

паспорт яисә шәхесне таныклый торган башка документ күчермәсен;

Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча физик затның салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсен, яисә индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ;

Премия дәгъвачысы тарафыннан имзаланган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт китабы күчермәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне.»;

5.11 пунктында «һөнәри сәнгать һәм сәнгать белеме бүлеге» сүзләрен «массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

7.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Премиягә лаек булган затларга Премия лауреатлары дипломнары һәм һәр номинация буенча 100 000 сум күләмендә акчалата бүләкләү тапшырыла.».

**Министр** **И.Х.Аюпова**